Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының
«Иске Гришкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
гражданнары җыены карары

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлеге составына керүче Карманково авылы торак
пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2019 елның 26 ноябреннән № 2

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкино авыл җирлеге составына керүче Карманково авылында гражданнар җыены карар итте:

1. Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкино авылы җирлегенең Карманково авылында теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2020 елда үзара салым акчаларын - 300 сум һәм 1, 2 төркем инвалидлар, 18 яшькә кадәр тәрбиядә булган күп балалы гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүгә чакырылган гражданнар өчен бер тапкыр түләнә торган түләүне киметергә, әлеге категориядәге гражданнар өчен 150 сум күләмендә түләү кертергә.

2. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрергә:

- Карманково авылы зиратына юл салу;
- Бөек Ватан сугышы вакытында һәлак булганнарга Карманково авылында стенд-һәйкәл урнаштыру.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Карманково авылы, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы В.В.Мамакова